ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШАДЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.18, с. Шадчи,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422145

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШӘДЧЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Яшьләр ур., 18 нче йорт, Шәдче авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422145

тел.(факс): (85563) 2-52-24; e-mail: Shad.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление
№ 21

Карар
«14» декабрь 2022ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017елның 22 декабрендәге 9 нчы санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең«Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең«Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 24 октябрендәге 1885 номерлы карарлары нигезендә, Шәдче авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы тотрыклылыкны арттыру максатларында Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Шәдче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә чүп, үләннәр, яфрак һәм башка калдыкларны, материалларны яки әйберләрне яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында»Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыШәдче авыл җирлегеБашкарма комитетының 2017елның 22 декабрендәге 9 нчы санлы карарына (алга таба- Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Каранын 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Шәдче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктларының гомуми файдаланудагы җирләрендә, шулай ук торак пунктлар территорияләрендә урнашкан шәхси йортлар территорияләрендә ризык әзерләү өчен махсус бүленгән һәм моның өчен җиһазландырылган урыннардан тыш ачык уттан файдалану, шулай ук чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яки эшләнмәләрне яндыру тыела.»

1.2. Каранык 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яндыру урыны итеп түбәндәге территорияләрне билгеләргә:

| N п/п | Торак пункт исеме | Чүп яндыру урыны | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Шәдче авылы | Торак пункттан көньяк-көнбатышка таба | Башкарма комитет |
| 2. | Вахит авылы | Торак пунктның көнбатыш өлешендә | Башкарма комитет |
| 3. | Юкәче авылы | Торак пунктның көнбатыш өлешендә | Башкарма комитет |
| 4. | Ямаш авылы | Торак пункттан көньяк-көнбатышка таба | Башкарма комитет |
| 5 | Яңа Мочалкино авылы | Торак пунктның көнбатыш өлешендә | Башкарма комитет |
| 6 | Иске Мочалкино авылы | Торак пунктның көнбатыш өлешендә | Башкарма комитет |
| 7 | Тәкәрлек бистәсе | Торак пунктның көнбатыш өлешендә | Башкарма комитет |

1.3. Түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:
«Чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яисә эшләнмәләрне яндыру ысулы - ачык учак дип билгеләргә.»
1.4. Түбәндәге эчтәлекле 2.2 пункт өстәргә:
«Чүп – чарны яндыруны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә башкарырга.»

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында , Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы

Шәдче авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе В.В.Шрыков